СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№15**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында Үрнәк авылы, Урман урамы, 45В нче йорты адресы буенча урнашкан Лесхоз мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында Үрнәк авылы, Урман урамы, 45В нче йорты адресы буенча Лесхоз мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында Үрнәк авылы, Урман урамы, 45В нче йорты адресы буенча Лесхоз мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында Үрнәк авылы, Урман урамы, 45В нче йорты адресы буенча Лесхоз мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Үзәк, Бакча, Тау асты, Наратлы урамнарында яшәүчеләр;
2 нче этап: Көнчыгыш, Төньяк, Болын, Елга арты урамнарында яшәүчеләр;
3 нче этап: Урман, Күпер, Дуслык урамнарында яшәүчеләр;
4 нче этап: Урман арты, Тынычлык, Көнбатыш урамнарында яшәүчеләр.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

1. Юл-урам челтәренә тигезләү катламы ясау:

Болын урамы - 100м., Наратлы урамы – 100м., Бакча урамы - 70м., Көнчыгыш урамы - 100м., Төньяк урам - 100 м.

2. Юл полотнасындагы чокырларны ремонтлау:

Тынычлык урамы - 100м., Урман урамыннан Урман арты урамына кадәр бару юлы – 200м.

3.Үрнәк бистәсендә балалар мәйданчыгына кече архитектура формалары сатып алу.

4. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

7. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында граждannарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк бистәсе, Урман урамы, 54А йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк бистәсе, Урман урамы, 1А йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк бистәсе, Бакча урамы, 3 нче йорт.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков